Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Больше-Машляковская средняя общеобразовательная школа» Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДАЮ |
| --- | --- | --- |
| Руководитель ШМО учителей гуманитарного цикла | Заместитель директора по УВР | Директор МБОУ «Больше-Машляковская СОШ» |
| ______________ | ______________( Дильмухаметова ЛР. ) | ______________( СтепановаЛ.А. ) |
| ( Мифтахова Г.Р. ) | от «29» 08 . 2023г | Приказ №177 от «29»08.2023 г. |
| Протокол №1 от "25" _08_ 2023 г. | | |

**Рабочая программа**
по внеурочной деятельности **«Татар теле җәүһәрләре»**
для 9 в класса МБОУ «Больш—Машляковская СОШ»
***Направление: общеинтеллектуальное***
Составитель: Мингазутдинова Ф.Г.
Учитель татарского языка и литературы

Рассмотрено на педсовете
Протокол №1 от 29. 08.2023 г.

2023-2024 уч.год

## Аңлатма язуы

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы мәгариф сәясәтенең төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә дә иркен аралашучы шәхес тәрбияләү. Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 маддәсендә һәм “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Законда күрсәтелгәнчә, Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә.

Федераль дәүләт белем стандартлары да укучыларның аралаша белү осталыгына, билгеле күләмдә тел байлыгына ия булуына, эзлекле фикерли белү сәләтенә, сөйләм күнекмәләренә ия булуын таләп итә.

Бу таләпләрне тормышка ашыруда тел һәм әдәбият дәресләре генә түгел, ә дәрестән тыш эшчәнлек тә зур файда китерә. Әлеге укыту формасы белем бирү процессының бер өлеше булып тора. Федераль дәүләт стандартлары бу эшчәнлекне тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Дәрестән тыш чараларның төп билгеләнеше – дәрестә каралган теоретик материалларны тирәнтен өйрәнү генә түгел, алган белемнәрен стандарт булмаган мәсьәләләр чишүдә куллана белү күнекмәләрен үстерү дә, мәсьәләләр белән эшләү культурасын тәрбияләү дә. Шулай ук балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелергә һәм үткәрү формасы буенча укытуның дәрес системасыннан аермалы булырга тиеш. Әлеге “Татар теле җәүһәрләре” дип аталучы дәрестән тыш эшчәнлек программасы шуларны истә тотып 9 нчы сыйныфның рус мәктәбендә укучы татар укучылары өчен төзелде.

Татар теле буенча оештырыла торган дәрестән тыш эшчәнлек – бөтен укыту-тәрбия процессының аерылгысыз бер өлеше. Дидактик, методик һәм гамәли яктан дөрес оештырылган дәрестән тыш эшчәнлек укучыларның белемнәрен киңәйтә. Әлеге эшчәнлекнең педагогик яктан әһәмияте тагын шунда, укучылар тел буенча дәреслектә булмаган кызыклы материаллар белән танышалар, дәрестән тыш чараларда катнашу нәтиҗәсендә алган белемнәрен дәрестәге мөстәкыйль эш вакытында да файдалана алалар.

Дәрестән тыш эшчәнлек эчтәлеге һәм планы укучыларның кызыксынуларыннан, яшь үзенчәлекләреннән чыгып төзелде.

Дәрестән тыш эшчәнлек эшләренең укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә аерым таләпләре дә бар:

- Укучылар теләп язылырга, ягъни ирекле рәвештә язылырга тиеш;
- Түгәрәкне үткәрү өчен метод һәм алымнарны сайлый белергә кирәк;
- Укучылар алган биремнәр авыр һәм катлаулы булмаска тиеш;

Балаларга татар теле һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәтүнең төп максаты – аларны бу телдә сөйләшергә, тыңлап аңларга, укырга һәм язарга, сүзләрне дөрес әйтә белергә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру. Ә татар баласы үз телендә аралаша белә, аңа дәресләр кызыксыз булып тоелырга мөмкин. Шуңа күрә, укучыларны артык мәҗбүр итмичә, фән белән кызыксындыра белү, аларда татар телендә аралашу ихтыяҗы тудыру мөһим максат булып тора. Мин бу максатны тормышка ашыру өчен татар халык мәдәниятына, традицияләренә мөрәҗәгать итәргә булдым. Халык традицияләрен белем бирү прцессында куллануның тәрбияви роле дә бик зур. Һәр халыкның үзенә хас традицияләре бар, әлбәттә. Ләкин традицияләр төрле булуга карамастан, максаты барысының да бер: киләчәк буынга тиешле тәрбия бирү. Халыкның иң күркәм гореф-гадәт һәм йолаларының милләтара мөнәсәбәтләрнең бүгенге катлаулы чорында дуслык, татулык урнаштыруда, яшь буынга белем һәм тәрбия бирү эшчәнлегендә терәк булып торуын һәркем ачык белә.

**Теманың актуальлеге**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен

баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Шуңа күрә мин “Татар теле җәүһәрләре” дип исемләнгән дәрестән тыш эшчәнлек программасы төзергә уйладым.

**Программаның максаты**:

Татарстан җирендә яшәп, рус мохитендә тәрбияләнеп, татар халкының тормыш-көнкүрешен күреп үсүче балаларга татар халкының бай әдәбияты үрнәкләре аша татар теленең бөеклегенә инандыру, телне өйрәнү мохитен тудыру, татар телендә аралашырга, үз фикерен белдерергә өйрәтү.

**Төп бурычлары:**

1. Укучыларның сүзлек хәзинәсен баету, аралаша белү күнекмәләрен камилләштерү, үзара дустанә хезмәттәшлек булдыру;
2. Танып-белү эшчәнлеген, иҗади фикерләү сәләтен камилләштерү;
3. Төркем эчендә эшли, фикерләрне тыңлый белү;
4. Укучыларны эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә тарту, нәтиҗә ясарга юнәлеш бирү.

**Төп таләпләр:**

- төп мәгълүматны алу аркылы әңгәмәдә, проект эшендә катнаша алуы;
- алынган мәгълүматка карата мөнәсәбәт белдерерү;
- проблемалы сорау куелган билгеле бер тема буенча диалог төзи, ситуатив күнегүләрне үти белү;
- кирәкле төшенчәләрне һәм терминнарны куллана белергә тиеш.

Программа 34сәгатькә исәпләнгән, 11 сәгате-теоретик материалларны өйрәнүгә, 23 сәгате-гамәли эшләргә,1 сәгате-укучыларның белемен тикшерүгә багышлана.

**Программаны тормышка ашыру шартлары:**

Рус телле балаларда татар теленә, сәнгатенә, мәдәниятенә, тарихына хөрмәт хисе тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү максатыннан, “Сабыйга”, “Салават күпере” журналлары, “Сабантуй” газетасы, “Мәгариф” журналларындагы материаллардан файдалану да отышлы дип саныйбыз. Җырлар шулай ук дәресне төрләндереп җибәрә, балалар татарча җырларга, сыйныфтан тыш чараларда катнашырга бик теләп ризалашалар. Бу бәйрәмнәрдә алар үзләренең матур итеп җырлый, бии, сәнгатьле итеп сөйли белү осталыгына ия булуларнын күрсәтәләр. Журналистлар булып, төрле темаларга интервьюлар алу да ошый аларга.Укучылар бик теләп проект эшләре белән дә шөгыльләнәләр. Нәтиҗәдә, балалар татар телен яратып, дәресләргә теләп йөриләр, татар телен өйрәнергә тырышалар. Район күләмендә уздырылган чараларда да актив катнашалар.

Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, түбәндәге **алымнар** кулланыла:

| **Мәгълүмат бирү алымнары:** | **1. Анализ алымнары:** | **2. эш алымнары** |
|---|---|---|
| • укытучы сүзе<br>• әсәргә иллюстрацияләр карау<br>• укытучы укуы<br>• аңлашылмаган сүзләрне аңлату<br>• аңлатмалар бирү<br>• чагыштыру<br>• китап тәкъдим итү<br>• китап күргәзмәсе | • әсәрне өлешләргә бүлү<br>• план төзү<br>• чагыштыру<br>• эчтәлек сөйләү<br>• әңгәмә<br>• эзләнү<br>• проблемалар чишү | • иҗади б<br>• сөйләү<br>• әсәрне с<br>• иллюстр<br>• текстны<br>• рәсем яс<br>• проект э<br>• уеннар<br>• экскурси буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**Көтелгән нәтиҗә:**

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**

Үз уңышларың, уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;

- Үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтияҗ формалаштыру.
- уку һәм танып белүгә битараф булмау, тормышка актив караштa тәрбияләнү;
- ирешкән нәтиҗәләрнең баланың рухи-әхлакый үсешенә, сәламәт һәм хәвеф-хәтәрсез яши белүенә бәйле булу.
  - укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
  - өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан мөстәкыйль файдалана алу;
  - мөстәкыйль рәвештә белем ала белү.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- Гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- Үз эшчәнлегеңне контрольгә алу , биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- Тормыш тәҗрибәсен куллану;
- Халык авыз иҗаты һәм автор әсәрләрен аера белү;
- Эшләгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре формалашу нәтиҗәләре** :

- Тормыш тәҗрибәсен куллану;
- Күршең белән, төркемнәрдә (зур һәм кечкенә) хезмәттәшлек итү;
- Ачыклый торган сораулар бирә белү;
- Эчтән һәм кычкырып аңлап уку;
- Төрле фикерләрне исәпкә алу һәм үз позицияңне нигезләү;
- Башкаларның фикерен тыңлый һәм үз фикереңне әйтә белү;
- Табигать һәм кешелек дөньясының бердәмлеге;
- Ялгыш фикерләрне вакытында тәнкыйтьли белү, хаталарны күрсәтү;
- Билгеле бер темага сөйләм төзи белү;

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре:**

- эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару;
- сызым, схема, таблица, шартлы рәсем, план күчерү, үзгәртү, төзү;
- охшашлык һәм аермалыкларны аеру, чагыштыру;
- бербөтенне өлешләргә бүлү;
- аерып алынган нигез буенча объектларны тәртипкә салу;
- нәтиҗә чыгару;
- охшашлыклар урнаштыру;
- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- проблеманы чишү алымнарын хезмәттәшлектә табу

**Предмет универсаль уку гамәлләре:**

- сөйләм әдәбе үрнәкләрен урынлы кулланып, сөйләшү үткәрү;
- укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча әңгәмә кору;
- аралашу ситуацияләренә бәйле диалог төзеп сөйләү (һәр укучының репликалар саны 6 дан ким булмаска тиеш);
- тасвирлау һәм хикәяләү элементларын кертеп, лексик тема буенча эзлекле сөйләм оештыру (җөмләләр саны 7 дән ким булмаска тиеш);
- укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләгәндә, төрле җөмлә калыпларын куллану

- телдән яки язма аралашу өчен, кирәкле тел берәмлекләрен куллана белү;

- татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен әйтә белү.

- татар теле дәресләренә карата уңай мөнәсәбәттә булу һәм телне кызыксынып өйрәнү, шулай ук гомуми һәм махсус күнекмәләргә ия булу һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерүгә әзер булу.

Программаны тормышка ашыру барышында укучылар бер-берсе белән аралашырга, төрле мәгълүмат белән эшләргә өйрәнергә, тикшеренү эшләре алып барырга, туган як, татар халкы мәдәнияты, традицияләре турында күбрәк мәгълүмат тупларга тиешләр.

**Сәгатьләр бүленеше.**

| № | Тема | Теоретик сәг. | Практик сәг. | Барлык сәг. саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | ***Белем—нур, белмәү — хур.*** Кереш дәрес. Программа белән таныштыру. | 1 | - | 1 |
| 2 | ***Халкыбызның күңел җәүһәрләре*** Балалар фольклоры. | 1 | 2 | 3 |
| 3 | ***Белем укудан башлана.*** Татар халык бәйрәмнәре | 1 | 5 | 6 |
| 4 | Татар халык ашлары | 1 | 1 | 2 |
| 5 | ***Халкымның күңел бизәкләре.*** Милли киемнәр | 1 | 1 | 2 |
| 6 | ***Минем исемем-минем язмышым.*** Татар исемнәре | 1 | 1 | 2 |
| 7 | ***Ямьле балачак.*** Татарча балалар журналларына күзәтү. | 1 | 1 | 2 |
| 8 | ***Укысаң – белерсең...*** Татар халык әкиятләре | 1 | 3 | 4 |
| 9 | ***Уйныйк та көлик!*** Мәзәкләр | 1 | 1 | 2 |
| 10 | ***Җырсыз кеше — канатсыз кош.*** Татар җырлары | 1 | 1 | 2 |
| 11 | ***Хыял дөньясында.*** Татар телевидениесе | 1 | 2 | 3 |
| 12 | Иҗади эшләргә корылган дәресләр | - | 4 | 4 |
| 13 | Йомгаклау | | 1 | 1 |
| | Барысы | 11 | 23 | 34 |